СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 60 от 30.06.2021

на № _от ________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Уставына үзгәрешләр һәм
өстәмәләр проекты турында

2014 елның 19 декабрендә кабул ителгән 281 номерлы Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставын "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131 номерлы Федераль законга һәм "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән 131 номерлы Россия Федерациясе Федераль законының 44 статьясына яраштыру максатыннан, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Саба муниципаль районы Советының "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставын яңа редакциядә кабул итү турында" 2014 елның 19 декабрендәге 281 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты буенча ачык тыңлауларны, Саба муниципаль районы Советының "Саба муниципаль районында ачык тыңлаулар турында нигезләмә проекты хакында"гы 2006 елның 21 ноябрендә кабул ителгән 94 номерлы карары белән расланган тәртиптә, 2021 елның 4 августында сәгать 9да ТР, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т. б., Г. Закиров урамы, 52 йорт адресы буенча урнашкан муниципаль район Башкарма комитеты бинасының актлар залында үткәрергә.

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына карата гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм аның турында фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен расларга.

4. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне 2021 елның 3 августына кадәр Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советына юлларга кирәк.

5. "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында" карар проектын Интернет челтәрендә - Татарстан

Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru. рәсми порталында;

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына карата гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм аның турында фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru. рәсми порталында;

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрү тәртибен Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru. рәсми порталында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының юридик бүлеге начальнигы А.И. Миникаевка йөкләргә.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р. Н. Минниханов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Советының 2021 елның
30 июнендә кабул ителгән
60 номерлы карарына
кушымта

# Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проекты

1. Уставның 41 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“41 Статья. Район Башлыгы вәкаләтләренең вакытыннан алда туктатылуы.

1. Район Башлыгы вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

1) үлем;

2) үз теләге белән отставкага китү;

3) “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 741 статьясы нигезендә отставкага җибәрү;

4) “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 74 статьясы нигезендә вазыйфадан ваз кичү.;

5) суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылу;

6) суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип тану яисә вафат булган дип игълан итү;

7) аңа карата судның гаепләү карарының законлы көченә керүе;

8) Россия Федерациясеннән читкә даими яшәү урынына чыгу;

9) Россия Федерациясе гражданлыгын туктату, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданы булган чит ил гражданлыгын туктату, аның нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы булмаган, Россия Федерациясе гражданының чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы чит ил гражданлыгын яки яшәүгә рөхсәт төрен яисә башка документ алу, аның нигезендә чит ил гражданлыгы булган Россия Федерациясе гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы;

10) сайлаучыларның, җирлекнең тиешле вәкиллекле органы депутаты буларак, чакыртып алулары;

11) суд тәртибендә сәламәтлек ягыннан муниципаль берәмлек Башлыгы вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга сәләтсез дип билгеләү;

12) “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә, муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору, шулай ук муниципаль берәмлек бетерелгән очракта;

13) муниципаль берәмлек чикләрен үзгәртү нәтиҗәсендә муниципаль берәмлек сайлаучылары санының 25% тан артуы.

2.. Район Башлыгының вәкаләтләре, шулай ук район Башлыгы, аларның ирләре-хатыннары һәм балигъ булмаган балалары тарафыннан “Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны, анда акча һәм кыйммәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында”гы 2013 елның 7 маенда кабул ителгән 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән тыю үтәлмәгән очракта, Россия Федерациясе Президентының ышанычы югалуга бәйле рәвештә, вакытыннан алда туктатыла.

3. Район Советы вәкаләтләре срогы тәмамланганчы алты айдан кимрәк вакыт калган булса, район Башлыгын сайлау яңа билгеләнгән район Советының беренче утырышында гамәлгә ашырыла.

4. Район Башлыгының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, яңа район Башлыгы, район Советының якындагы утырышында, вәкаләтләре шул рәвешле туктатылган көннән алып алты айдан артмаган вакыт эчендә сайлана.

Район Башлыгының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган көннән алып алты ай узгач, район Советының яңа Башлыгы сайлана торган утырышы районның яше буенча иң өлкән депутаты тарафыннан алып барыла.

Әгәр дә аның өчен район Советы депутатларының билгеләнгән санының яртысыннан күбрәге тавыш бирсә, депутат район Башлыгы булып сайлана.

5. Район Башлыгының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган яки суд карары буенча аңа карата сак астына алу яисә вазыйфасыннан вакытлыча читләштерү рәвешендә процессуаль мәҗбүр итү чаралары кулланылган очракта, аның вәкаләтләрен район Башлыгы урынбасары башкара.

Район Башлыгы урынбасары булмаганда, район Башлыгы вәкаләтләрен вакытлыча район Советы депутаты башкара, ул район Советының якындагы утырышында башка депутатлар, инициативалы депутатлар тарафыннан тәкъдим ителгән кандидатлар арасыннан сайлана.

Район Башлыгы вәкаләтләренең район Башлыгы урынбасары яки район Советы депутаты тарафыннан үтәлү срогы элеккеге район Башлыгының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган көннән алып алты айдан артмаска тиеш.”.

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Советының 2021 елның
30 июнендә кабул ителгән
60 номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына карата гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм аның турында фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибе.**

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Уставына кертелә торган үзгәрешләр һәм өстәмәләр проектына тәкъдимнәр, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советына, 422060, ТР, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т. б., Г. Закиров урамы, 52 йорт, 315 кабинет адресы буенча, язма рәвештә Саба муниципаль районы Советының оештыру бүлеге начальнигына кертелә.

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 16.30 сәгатькә кадәр Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында басылып чыккан көннән алып кабул ителә.

2. Чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар 422060, ТР, Саба районы, Байлар Сабасы ш.т. б., Г. Закиров урамы, 5 йорт, 315 кабинет адресы буенча шәхсән тапшырыла яки почта аша җибәрелә (Конвертта “Устав турында фикер алышу” дигән тамга булырга тиеш).